Республика Татарстан
Глава Татарско-Челнинского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
423641, Менделеевский район,
с.Татарские Челны,
ул. Победы, д 3А

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлеге
Башлыгы
423641, Менделеевск районы, Татар Чаллысы авылы,
Җиңү урамы, 3А

тел./факс 8/85549/3-42-23, E-mail: Tcn.men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 19 ноябреннән №2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Татар-Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. 2022 елның 29 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 29 ноябрендә 18.00 сәгатькә Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча икенче этабын билгеләргә.

3. Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп Татар Чаллысы авылы, Җиңү урамы, 3А адресы буенча Татар Чаллысы авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Халык исемлеген Татар Чаллысы белән икегә аеруны территориаль билгеләр буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Яшел урам 1 йорттан 8 йортка кадәр, Төньяк урамы 1 йорттан 4 йортка кадәр, Җиңү урамы, 1 йорттан, 12 йортка кадәр, Мәктәп урамы, 3 йорттан 5 йортка кадәр

Икенче этап: Тынычлык урамы 1 йорттан 29 йортка кадәр, Яшьләр урамы 1 йорттан 22 йортка кадәр, Мохначев урамы 1 йорттан 9 йортка кадәр

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, белем алучы студентлардан тыш, 2023 елда үзара салым кертүне 1000 сум күләмендә билгеләргә һәм җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә ризамы:

**1. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:**
**- тау битендәге чокыр аша, «Челнинка» елгасына чаклы, гомуми арасы 250 метр булган металл баскыч ясау һәм монтажлау**
**- үлән чабу**
**- Балалар мәйданчыгы коймаларын урнаштыру**
**- Балалар спорт җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру.**

«Риза" "Каршы"

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Татар Чаллысы авыл җирлеге» бүлегендә www.mendeleevsk.tatar.ru һәм мәгълүмат стендларында кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә урнаштырырга

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Кузнецова Т.П